КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1034

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген камилләштерү чаралары турында» 2006 ел, 31 август, 441 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген камилләштерү чаралары турында» 2006 ел, 31 август, 441 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 31 гыйнвар, 52 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 734 нче; 2018 ел, 19 апрель, 264 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары басылып чыккан көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын кабул итү, алар үз көчен югалткан дип тану яки, тиешле актларны әзерләү вакытларын күрсәтеп, аларга үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Премьер-министрына җибәрергә;»;

сигезенче абзацта «федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән күздә тотылган» сүзләрен «федераль законнарны, Россия Федерациясе Президенты указларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын кабул итүгә бәйле рәвештә таләп ителә торган» сүзләренә алыштырырга;

тугызынчы абзацта «30 көн» сүзләрен – «60 көн» сүзләренә, «законнар белән күздә тотылган» сүзләрен «законнар бастырып чыгаруга (кабул итүгә) бәйле рәвештә таләп ителә торган» сүзләренә алыштырырга;

унынчы абзацта «законнар белән күздә тотылган» сүзләрен «законнар бастырып чыгаруга (кабул итүгә) бәйле рәвештә таләп ителә торган» сүзләренә алыштырырга;

4 нче пунктта:

икенче абзацта «закон проектларын» сүзләрен «норматив документлар» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзацта «законнар белән күздә тотылган» сүзләрен «законнар бастырып чыгаруга (кабул итүгә) бәйле рәвештә таләп ителә торган» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин